http://tatarfantast.moy.su/





## Киләчәккә ышаныч

Без еш кына әдәбиятыбызның байлыгы, зурлыгы белән мактанырга, горурланырга яратабыз, һәм хаклы рәвештә горурланабыз. Тик ни гаҗәп: шундый зур әдәбиятыбызда күпләрнең «теше үтми» торган жанрлар да бар. Ул жанрларны, нигездә, ялгызак язучылар үзләренең иңнәрендә күтәреп баралар. Мәсәлән, тарихи роман жанрында әлегә бердәнбер Н.Фәттах эшли, документаль проза өлкәсендә, башлыча, Ш.Рәкыйпов кына «тир түгә», балалар әдәбиятындагы әкият жанры бары Батулланы гына җәлеп итә. Тагын шундый бер өлкә бар: татар әдәбиятында бик сирәк очрый торган жанр — фәнни фантастика. Шулай дигәндә, без, әлбәттә, язучы Адлер Тимергалинны күз алдында тотабыз, һәм, хаклы рәвештә, татар әдәбиятының бердәнбер фантаст-язучысы дип йөртәбез.

Фәнни фантастика, беркемгә дә сер түгел, иң күп көч сорый торган, язучыдан тирән белем, киң эрудиция таләп итә торган өлкә. Әгәр шушы ФТР заманында физиканы, химияне, математиканы, шулай ук астрономияне, медицинаны белмәсәң, генетикадан, автоматикадан, кибернетикадан, бионикадан хәбәрдар булмасаң, әлеге фән нигезләрен тирәнтен төшенмәсәң, фантастика сине үзенә якын да җибәрми. А.Тимергалин исә барлык белеме, эрудициясе, үзенең фикер сөреше белән — физик, җаны, табигате белән — нечкә күңелле лирик. Аны нәкъ менә шушы ике сыйфат фантаст иткәндер дә.

А.Тимергалин — үзенең замандашларыннан бик күпкә алдан яшәүче язучы. Аның геройлары да — киләчәк чор кешеләре. Әсәрдәге вакыйгалар, күренешләр дә — ерак киләчәк күренешләре. Димәк, автор үзе дә күңеле, уй-хыяллары белән шул чорда, без күз алдына да китерә алмый торган Киләчәктә яши. Ләкин моның өчен язучының бүгенге тормышта кайнап яшәве, бүгенгенең шатлык-борчуларын тирәнтен аңлавы, тарихның асылын төшенүе, кешелекнең һәм җәмгыятьнең актив гражданины булуы шарт. Киләчәктә кешелек, яшәеш нинди<br>рәк булыр? Кешеләрнең холык-фигыльләре кайсы яклары белән ачылыр? Кеше кайсы сый-

фатларын югалтыр, кайсылары сакланып калыр? Кадерлебез Җирне киләчәктә нинди язмыш көтә? Язучыны менә шушы сораулар борчый. Бүген һәм киләчәктә хәл ителәсе кичектергесез проблемалар, дөньяның иң күренекле гыйлем ияләрен, гыйльми институтларны туктаусыз борчыган, дулкынландырган проблемалар, дөньяви мәсьәләләр тынгы бирми аңа. Ул эзләнә, өйрәнә, анализлый, нәтиҗәләр ясый, үзенең әсәрләрендә укучыларга ерак киләчәкнең үзе уйлап тапкан модельләрен тәкъдим итә, үзенең хыялында туган дөньяны укучылары белән бүлешә. Ләкин күпме генә талантлы булсаң да, башыңа килгән һәрбер фантазияне укучыга тәкъдим итеп булмый. Әсәр ышандырырга, фәнни булырга тиеш! А.Тимергалинның әсәрләре әнә шул көчкә — ышандыру көченә ия.

Язучы үзенең әсәрләрендә кайсыдыр фәнне пропагандалауны, яңа гыйльми идеяләр эзләүне үзмаксат итеп куймый, ә күтәрелгән мәсьәләләрне сәнгатьчә хәл итүне, сурәтләнгән вакыйгаларны социаль-эстетик яктан бәяләүне күздә тота. Шуңа күрә дә А.Тимергалин фантастикада техник проблемаларны түгел, әхлакый проблемаларны алгы планга куя. Аның геройлары ерак киләчәктә дә КЕШЕ булып калалар. Кеше үзен табигатьнең аерылмас бер кисәкчәсе итеп тоя икән, ул әле кешелеген югалтмый, җирне, кешелекне (димәк, үзен дә!) юкка чыгарырга сәләтле варвар була алмый дигән фикер уздыра автор. Бу мәсьәлә бер А.Тимергалинны гына борчымый, әлбәттә. Бу — уртак борчылуыбыз. Мәсәлән, атаклы Америка фантасты Рэй Брэдбериның «Һәм күкләр күкрәде» исемле мәгълүм хикәясен беләбез. Андагы күбәләк табигатькә сакчыл, кешелекле мөнәсәбәтнең символы дәрәҗәсенә күтәрелгән. Андый җан иясе А.Тимергалинда да бар. Аның «Көрәшү» хикәясе болай тәмамлана: «Коңгыз канатларын ачкалап та япкалап маташты, ахырда рәткә китерде дә, җир тартымын җиңеп, һавага күтәрелде һәм туп-туры ачык тәрәзәгә юл тотты». Юк, рухын төшерми язучы: табигать яши, тантана итә.

А.Тимергалинның «Роберт, уян, сөеклем!» исемле беренче хикәясе басылып чыгуга да егерме ике ел вакыт үтеп китте. Аннан соң инде язучының фантастик һәм маҗаралы хикәя-повестьлары тупланган сигез китабы дөнья күрде. «Ерак планетада», «Мәңгелек хатирәләр», «Адашкан йолдыз» кебек китапларын укучылар аеруча яратып укыйлар. Ул балалар өчен генә түгел, балаларның үзләре турында да яза. Мәсәлән, аның «Кырмыска тыкрыгы» һәм «Таш алиһә» исемле маҗаралы повестьлары бүгенге мәктәп балалары тормышыннан алып язылган. Алар укучыларны батырлыкка, Ватанны яратырга өнди, әхлаклылыкка өйрәтә.

Язучылар союзының балалар әдәбияты секциясе башлыгы Адлер Тимергалин һәрчак актив иҗади тормыш белән яшәп яши. Без аны тарихыбызны, культурабызны тирәнтен белүче, туган телебезнең үсешенә үзеннән зур өлеш керткән тел галиме дип тә беләбез. Аның татар фәнни терминологиясе үсешенә керткән хезмәтләре дә хуплауга, мактауга лаек. Физика, астрономия, техника, авыл хуҗалыгы, химия һәм биология буенча русча-татарча сүзлекләр төзүдә актив катнашуы әнә шул хакта сөйли. Әдип соңгы вакытта «Канатлы сүзләр» исемле күләмле хезмәтен тәмамлады. Ул да укучыларга олы бүләк булыр дип уйлыйбыз.

Адлер Тимергалин иҗат итә. Аңа җиңел түгел. Беренчеләргә һәрчак авыр. Бердәнберләргә тагын да авыррак. Ләкин ул — оптимист. Ул — эш кешесе, иҗат кешесе. Ул менә ничә еллар инде үзенә глобаль планеталарны, йолдызларны, гасырларны, чорларны, үзенә сыйдырган татар фантастикасын үз иңендә күтәреп бара. Әлбәттә, авыр, әмма мәртәбәле йөктер бу!

*1981*

чыганак: http://www.tatknigafund.ru/books/1079